| СОВЕТ БАВЛИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ БАУЛЫ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ СОВЕТЫ |
| --- | --- |

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

12.12.2019 Баулы шәһәре № 241

Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районы Советының 2014 елның 11 ноябрендәге 239 номерлы «Татарстан Республикасы «Баулы муниципаль районы» муниципаль берәмлегендә муниципаль вазыйфаларны биләүгә дәгъва итүче гражданнарның керемнәре, милекләре һәм милки характердагы йөкләмәләре турында, шулай ук Татарстан Республикасы «Баулы муниципаль районы» муниципаль берәмлегендә муниципаль вазыйфаларны биләүче затларның керемнәре, чыгымнары, милекләре һәм милки характердагы йөкләмәләре турында мәгълүмат бирү хакындагы нигезләмәне раслау турында» гы карарына үзгәрешләр кертү хакында

“Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында” Федераль законның 40 статьясына һәм “Коррупциягә каршы тору турында” Федераль законның 13.1 статьясына үзгәрешләр кертү хакында” 2019 елның 26 июлендәге 228-ФЗ номерлы Федераль закон, «Коррупциягә каршы тору мәсьәләләре буенча Татарстан Республикасының аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2019 елның 9 декабрендәге 99-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы нигезендә Баулы муниципаль районы Советы КАРАР ИТТЕ:

Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районы Советының 2014 елның 11 ноябрендәге 239 номерлы карары белән расланган (Баулы муниципаль районы Советының 2009 елның 20 апрелендәге 260нчы карары белән кертелгән үзгәрешләр белән) Татарстан Республикасы «Баулы муниципаль районы» муниципаль берәмлегендә муниципаль вазыйфаларны биләүгә дәгъва итүче гражданнарның керемнәре, милекләре һәм милки характердагы йөкләмәләре турында, шулай ук Татарстан Республикасы «Баулы

муниципаль районы» муниципаль берәмлегендә муниципаль вазыйфаларны биләүче затларның керемнәре, чыгымнары, милекләре һәм милки характердагы йөкләмәләре турында мәгълүмат бирү хакындагы нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

1. 7 пунктта «муниципаль вазыйфа биләүче зат» сүзләреннән соң «(авыл җирлекләренең вәкиллекле органнары депутатларының муниципаль вазыйфаларын биләүче һәм үз вәкаләтләрен даими булмаган нигездә гамәлгә ашыручы затлардан тыш)» сүзләрен өстәргә.

2. 7 пунктны түбәндәге эчтәлекле 7.1 пунктчасы белән өстәргә::

«7.1 Авыл җирлегенең вәкиллекле органы депутаты муниципаль вазыйфасын биләүче һәм үз вәкаләтләрен даими булмаган нигездә башкаручы зат депутат булып сайланганнан соң, аңа вакантлы депутат мандатын тапшырганнан соң яисә даими нигездә вәкаләтләрен гамәлгә ашыру туктатылганнан соң дүрт ай эчендә керемнәре, чыгымнары, милке һәм милки характердагы йөкләмәләре турында белешмәләр тапшыра, шулай ук, «Дәүләт вазыйфаларын биләүче затларның һәм башка затларның чыгымнары аларның керемнәренә туры килүен тикшереп тору турында»гы 2012 елның 3 декабрендәге 230-ФЗ номерлы Федераль законның 3 статьясындагы 1 өлешендә каралган алыш-биреш кылган очракта, мәгълүматлар тапшыру елына (хисап чорына) кадәрге һәр ел өчен. Хисап чоры дәвамында мондый алыш-биреш башкарылмаган очракта, күрсәтелгән зат бу хакта Татарстан Республикасы Президентына әлеге статьяның 2нче пунктында каралган махсуслаштырылган мәгълүмат ресурсыннан файдаланып, әлеге карарга кушымта нигезендәге формада белдерү кәгазе юллау юлы белән хәбәр итә. Әлеге пунктта каралган хәбәрнамә, шулай ук белешмәләр (хисап чоры дәвамында «Дәүләт вазыйфаларын биләүче затларның һәм башка затларның чыгымнары аларның керемнәренә туры килүен тикшереп тору турында» 2012 елның 3 декабрендәге 230-ФЗ номерлы Федераль законның 3 статьясындагы 1 өлешендә каралган алыш-бирешләр башкарылган очракта) хисап чорыннан соң килгән елның 30 апреленнән дә соңга калмыйча бирелә.

Авыл җирлеге вәкиллекле органы депутаты муниципаль вазыйфасын биләүче һәм үз вәкаләтләрен даими булмаган нигездә башкаручы зат тарафыннан имзаланган кәгазьдәге хәбәрнамәнең күчермәсе Баулы муниципаль районында коррупцион һәм башка хокук бозуларны профилактикалау эше өчен җаваплы вазыйфаи затка җибәрелә һәм закон нигезендә сакланылырга тиеш.»;

3. 9нчы пунктта “5нче пунктта күрсәтелгән срок” сүзләрен «7 пунктта, 7.1 пунктчада күрсәтелгән сроклар» сүзләренә алмаштырырга.

4. 16нчы пунктны түбәндәге эчтәлекле 16.1, 16.2, 16.3 пунктчалар белән тулыландырырга:

«16.1 Депутат, җирле үзидарәнең сайланулы органы әгъзасы, җирле үзидарәнең сайланулы вазыйфаи заты “Коррупциягә каршы тору турында”гы 2008 елның 25 декабрендәге 273-ФЗ номерлы Федераль закон һәм башка федераль законнар белән билгеләнгән чикләүләрне, тыюларны үтәргә, вазыйфаларны үтәргә тиеш.

Җирле үзидарәнең сайланулы органы депутаты, әгъзасы, җирле үзидарәнең сайланулы вазыйфаи заты вәкаләтләре "Коррупциягә каршы тору турында" 2008 елның 25 декабрендәге 273-ФЗ номерлы Федераль закон, "Дәүләт вазыйфаларын биләүче затларның һәм башка затларның чыгымнары аларның керемнәренә туры килүен тикшереп тору турында" 2012 елның 3 декабрендәге 230-ФЗ номерлы Федераль закон, "Аерым категория затларга Россия Федерациясе территориясеннән читтә урнашкан чит ил банкларында счетлар (кертемнәр) ачу һәм аларга ия булу, акча һәм кыйммәтле әйберләр саклау, чит ил финанс инструментларына ия булу һәм (яки) алардан файдалану тыелу турында”гы 2013 елның 7 маендагы 79-ФЗ номерлы Федераль закон белән билгеләнгән чикләүләрне, тыюларны, бурычларны үтәмәгән очракта, әгәр әлеге Федераль законда башкасы каралмаган булса, вакытыннан алда туктатыла.

16.2 Муниципаль вазыйфаларны, җирле администрация башлыгы вазыйфасын биләүне дәгъвалаучы гражданнар һәм җирле администрация башлыгы вазыйфаларын биләүче затлар тарафыннан бирелгән керемнәр, чыгымнар, милек һәм милек характерындагы йөкләмәләр турындагы

белешмәләрнең дөреслеген һәм тулылыгын тикшерү (алга таба - тикшерү) Татарстан Республикасы Президенты карары буенча гамәлгә ашырыла. Карар муниципаль вазыйфаны, җирле администрация башлыгы вазыйфасын, муниципаль вазыйфаны, җирле администрация башлыгы вазыйфасын биләүче затка карата аерым кабул ителә һәм язма рәвештә рәсмиләштерелә.

16.3 Әлеге статьяның 16.2 пунктында күрсәтелмәгән муниципаль вазыйфаны, шулай ук шулай ук җирле администрация башлыгы вазыйфасын биләүче зат тарафыннан бирелгән керемнәр, чыгымнар, милек һәм милек характерындагы йөкләмәләр турындагы белешмәләрнең дөреслеген һәм тулылыгын тикшерү нәтиҗәсендә, «Коррупциягә каршы тору турында» Федераль закон, «Дәүләт вазыйфаларын биләүче затларның һәм башка затларның чыгымнарының аларның керемнәренә туры килүен тикшереп тору турында” Федераль закон, «Аерым категория затларга Россия Федерациясе территориясеннән читтә урнашкан чит ил банкларында счетлар (кертемнәр) ачу һәм аларга ия булу, акча һәм кыйммәтле әйберләр саклау, чит ил финанс инструментларына ия булу һәм (яки) алардан файдалану тыелу турында»гы Федераль закон нигезендә билгеләнгән чикләүләр, тыюлар, вазыйфаларны үтәмәү ачыелганда, Татарстан Республикасы Президенты муниципаль вазыйфа биләүче затның вәкаләтләрен вакытыннан алда туктату, җирле администрация башлыгы вазыйфасын биләүче затның вәкаләтләрен вакытыннан алда туктату яисә аңа карата башка дисциплинар җәзаны куллану турында гариза белән тиешле карар кабул итәргә вәкаләтле җирле үзидарә органына яки судка мөрәҗәгать итә.»;

16.3.1 Керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында дөрес яки тулы булмаган мәгълүмат биргән депутатка, җирле үзидарәнең сайланулы органы әгъзасына, җирле үзидарәнең сайланулы вазыйфаи затына, әгәр бу мәгълүматларны бозып күрсәтсәләр, түбәндәге җаваплылык чаралары кулланылырга мөмкин:

1) кисәтү;

2) депутатны, җирле үзидарәнең сайланулы органы әгъзасын муниципаль берәмлекнең вәкиллекле органында, җирле үзидарәнең сайланулы органындагы вазыйфасыннан азат итү, аның вәкаләтләре вакыты туктатылганчы муниципаль берәмлекнең вәкиллекле органында, җирле үзидарәнең сайланулы органында вазыйфа биләү хокукыннан мәхрүм итү.;

3) вәкаләтләрне гамәлгә ашырудан даими нигездә азат итү, вәкаләтләр срогы туктатылганчы даими нигездә вәкаләтләрне гамәлгә ашыру хокукыннан мәхрүм итү;

4) муниципаль берәмлекнең вәкиллекле органында, җирле үзидарәнең сайланулы органында аның вәкаләтләре срогы туктатылганчы вазыйфаларны биләүне тыю;

5) вәкаләтләр срогы туктатылганчы даими нигездә вәкаләтләрне үтәүне тыю.

16.3.2. Татарстан Республикасы Президентының әлеге статьяның 16.3.1 пунктчасында каралган җаваплылык чараларын куллану турында гаризасы (алга таба – җаваплылык чаралары) аларны куллану турында карар кабул итәргә вәкаләтле җирле үзидарә органы тарафыннан әлеге органга гариза кергән көннән соң 30 көннән дә соңга калмыйча карала. Җаваплылык чараларын куллану турында карар кабул итәргә вәкаләтле җирле үзидарә органы эшенең төп формасы сессия һәм җаваплылык чараларын куллану турында Татарстан Республикасы Президенты гаризасы сессияләр арасында чорда кергән булса, әлеге гариза ул кергән көннән өч айдан да соңга калмыйча карала. Татарстан Республикасы Президенты гаризасын карау нәтиҗәләре буенча җаваплылык чарасын куллану яисә җаваплылык чарасын кулланудан баш тарту турында карар кабул ителә.

Хисап чорында керемнәр, чыгымнар, милек һәм милек характерындагы йөкләмәләр турында дөрес булмаган яки тулы булмаган мәгълүмат биргән өчен бары тик бер җаваплылык чарасы гына кулланылырга мөмкин.

Керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында дөрес яисә тулы булмаган белешмәләр биргән депутатка, җирле

үзидарәнең сайланулы органы әгъзасына, җирле үзидарәнең сайлап куелган вазыйфаи затына аңа карата җаваплылык чараларын куллану турында карар кабул итәргә вәкаләтле орган, кимендә биш көн алдан, язма рәвештә аңа карата җаваплылык чараларын куллану турындагы мәсьәләне карау турында хәбәр итә.

Җаваплылык чарасын куллану турындагы карарда коррупциячел хокук бозу турында язма, депутат, җирле үзидарәнең сайланулы органы әгъзасы, җирле үзидарәнең сайланулы вазыйфаи заты тарафыннан бозылган норматив хокукый актлар нигезләмәләре, Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән тәртиптә карарга шикаять бирү хокукы турында язма булырга тиеш.

Җаваплылык чарасын кулланудан баш тарту турындагы карарда мондый баш тартуны дәлилле нигезләү булырга тиеш.

Җаваплылык чарасын кулланудан баш тарту турындагы карарда мондый баш тартуны дәлилле нигезләү булырга тиеш.

Җаваплылык чарасын куллану яисә җаваплылык чарасын кулланудан баш тарту турында карарның күчермәләре аны кабул иткән көннән соң биш эш көне эчендә депутатка, җирле үзидарәнең сайланулы органы әгъзасына, җирле үзидарәнең сайланулы вазыйфаи затына имза куеп тапшырыла яисә почта аша юллана, шулай ук Татарстан Республикасы Президентына җибәрелә.

Җаваплылык чарасын куллану яисә җаваплылык чарасын кулланудан баш тарту турындагы карарга карата Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән тәртиптә шикаять бирелергә мөмкин.»

Баулы муниципаль районы Башлыгы,
район Советы Рәисе Р.Х. Гатиятуллин

Баулы
муниципаль районы Советының
2019 елның 12.12. кабул ителгән
241 номерлы карарына
кушымта

Татарстан Республикасы Президентына
________________________________

Хәбәрнамә

Мин, ____________________________________________муниципаль районы
муниципаль районы атамасы
_______________________________________авыл җирлеге депутаты
авыл җирлегенең вәкиллекле органы

___________________________________________________________________________,
фамилия, исем һәм әтисенең исеме (булганда)
«___»____________ ________ елда туган, паспорт серия ______
№_______________, _______________________________________________
паспортны биргән орган һәм вакыты
___________________________________________________________________________,

«Коррупциягә каршы тору турында» 2008 елның 25 декабрендәге 273-ФЗ номерлы Федераль законның 121 статьясындагы 42 өлеше һәм «Муниципаль вазыйфаны йә контракт буенча җирле администрация башлыгы вазыйфасын биләүгә дәгъвә кылучы затлар яки муниципаль вазыйфа йә контракт буенча җирле администрация башлыгы вазыйфаларын биләүче затлар тарафыннан керемнәр, чыгымнар, мөлкәт һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр турында белешмәләр бирү тәртибе хакында"гы 2017 елның 19 июлендәге 56-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 2 статьясындагы 41 өлеше нигезендә Сезгә хәбәр итәм: мин, минем (ирем яки хатыным) һәм (яки) балигъ булмаган балаларым тарафыннан 20____елның 1 гыйнварыннан 31 декабрьгә кадәр чорда - отчет чорында гомуми суммасы безнең (минем һәм иремнең (хатынымның) соңгы өч еллык керемнәребездән арткан, «Дәүләт вазыйфаларын биләүче затларның һәм башка затларның чыгымнарының аларның керемнәренә туры килүен тикшереп тору турында» 2012 елның 3 декабрендәге 230-ФЗ номерлы Федераль законның 3 статьясындагы 1 өлешендә каралган алыш-бирешләр (җир участогы, башка күчемсез милек объекты, транспорт чарасы, кыйммәтле кәгазьләр, акцияләр (оешмаларның устав (җыелма) капиталларында катнашу өлеше, пайлары) сатып алу буенча килешүләр) ясалмады.

Бу мәгълүматларның дөреслеген раслыйм.
«____»_____________ 20__ ел.
_________________________________
хәбәрнамә биргән затның имзасы

___________________________________________________________________________
(хәбәрнамәне кабул итүгә вәкаләтле затның фамилиясе, исеме һәм әтисенең исеме (булган очракта) һәм имзасы)».